**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 апрель № 286

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 октябрь, 744 нче, 2015 ел, 25 февраль, 113 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле яңа 5.3 – 5.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«5.3. Дәүләт комитеты эшчәнлегенең аеруча мөһим мәсьәләләре Дәүләт комитеты коллегиясе утырышларында карап тикшерелә.

5.4. Дәүләт комитеты коллегиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Дәүләт комитеты рәисе белән Дәүләт комитеты коллегиясе арасында фикер каршылыклары килеп чыккан очракта Дәүләт комитеты рәисе үз карарын чыгара. Килеп чыкккан каршылыклар хакында Дәүләт комитеты рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итә.

5.5. Дәүләт комитеты коллегиясе саны һәм составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

5.3 пунктны 5.6 пункт дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\286.doc